# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Лаеш муниципаль районы Караеш һәм Нармонка авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм "Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Лаеш муниципаль районы составына керүче "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеген һәм "Караеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеген җирлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан белдерелгән шушы җирлекләр халкы ризалыгы белән әлеге авыл җирлекләрен "Нармонка авыл җирлеге"нә (алга таба – яңа төзелгән "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге) берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы һәм аның башлыгы вәкаләтләре срогын биш ел дип билгеләргә.

2. Яңа төзелгән "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы ун депутаттан тора дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, әзерләү һәм уздыру законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумда кабул ителә торган муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарда башкасы билгеләнмәсә, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) яңа төзелгән "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан үз составыннан яшерен тавыш бирү юлы белән беренче утырышында сайлана.

Яңа төзелгән "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан артыграгы аны сайлау өчен тавыш бирсә, әлеге муниципаль берәмлек башлыгы итеп сайланган дип санала.

Яңа төзелгән "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгын сайлаганчы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышын вәкиллекле органның иң өлкән яшьтәге депутаты ача һәм алып бара;

2) яңа төзелгән "Нармонка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең сайланган башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

"Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2010, 1 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;


б) ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Нармонка авыл җирлеге: Нармонка авылы (административ үзәк), Карадүле, Караеш, Тетеево, Астраханка, Татар Кабаны авыллары;";

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Лаеш муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
41 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *1(41) - 9(45)* | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| *9(45) - 35(56)* | - Питрәч муниципаль районы |
| *35(56) - 33(57)* | - Балык Бистәсе муниципаль районы |
| *33(57) - 51(32)* | - Алексеевск муниципаль районы |
| *51(32) - 50(33)* | - Спас муниципаль районы |
| *50(33) - 7(42)* | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| *7(42) - 1(41)* | - Югары Ослан муниципаль районы |

"Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Лаеш шәһәре |
| 2 | Александровка авыл җирлеге |
| 3 | Атабай авыл җирлеге |
| 4 | Олы Кабан авыл җирлеге |
| 5 | Габишев авыл җирлеге |
| 6 | Державино авыл җирлеге |
| 7 | Егорьево авыл җирлеге |
| 8 | Хәерби авыл җирлеге |
| 9 | Көек авыл җирлеге |
| 10 | Макаровка авыл җирлеге |
| 11 | Keче Елга авыл җирлеге |
| 12 | Матюшино авыл җирлеге |
| 13 | Нармонка авыл җирлеге |
| 14 | Никольский авыл җирлеге |
| 15 | Орел авыл җирлеге |
| 16 | Пәрәү авыл җирлеге |
| 17 | Комлы Кавал авыл җирлеге |
| 18 | Рождествено авыл җирлеге |
| 19 | Сокуры авыл җирлеге |
| 20 | Урта Девятово авыл җирлеге |
| 21 | Столбище авыл җирлеге |
| 22 | Татар Сараланы авыл җирлеге |
| 23 | Татар Янтыгы авыл җирлеге |
| 24 | Чырпы авыл җирлеге"; |

3) 9 нчы кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Егорьево авыл җирлеге Александровка, Державино, Хәерби, Көек, Нармонка, Пәрәү, Сокуры авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы белән чиктәш.";

б) сигезенче абзацта "Егорьево, Караеш һәм Көек" сүзләрен "Егорьево, Көек һәм Нармонка" сүзләренә алмаштырырга;

в) тугызынчы абзацта "Караеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә һәм "Егорьево, Караеш һәм Хәерби" сүзләрен "Егорьево, Хәерби һәм Нармонка" сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 нчы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 11 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Караеш" сүзен "Нармонка" сүзенә алмаштырырга;

б) җиденче абзацта "Егорьево, Караеш һәм Хәерби" сүзләрен "Егорьево, Хәерби һәм Нармонка" сүзләренә алмаштырырга;

в) сигезенче абзацта "Караеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә һәм "Караеш, Хәерби һәм Никольский" сүзләрен "Хәерби, Нармонка һәм Никольский" сүзләренә алмаштырырга;

6) 12 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Караеш," сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта "Караеш һәм Көек" сүзләрен "Көек һәм Нармонка" сүзләренә алмаштырырга;

в) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Көек авыл җирлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,2 км көнбатышка таба "Лаеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап сазлыкка кадәр, шуннан соң сазлыкның көньяк чиге буйлап 600 м уза, аннары 1,1 км төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев сусаклагычының яр буе линиясенә кадәр бара, алга таба шул ук юнәлештә сусаклагыч яры буйлап 1,1 км, аннары 400 м төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы буйлап һәм 6,0 км көньяк-көнчыгышка таба 21 нче тоташу ноктасына кадәр барып җитә.";

г) тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 16 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта "Караеш" сүзен "Егорьево, Хәерби" сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта "Караеш, Нармонка һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Беляково авылыннан 2,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып" сүзләрен "Хәерби, Нармонка һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Травкино авылыннан 700 м

көньякта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба Столбище – Атабай автомобиль юлы буйлап, аннары" сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Нармонка авыл җирлеге чиге Көек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Егорьево, Хәерби һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көек авылыннан 2,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,2 км көнбатышка таба "Лаеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап сазлыкка кадәр, шуннан соң сазлыкның көньяк чиге буйлап 600 м уза, аннары 1,1 км төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев сусаклагычының яр буе линиясенә кадәр бара, алга таба шул ук юнәлештә сусаклагыч яры буйлап 1,1 км уза, аннары 400 м төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы буйлап һәм 6,0 км көньяк-көнчыгышка таба Көек, Нармонка һәм Рождествено авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=438066,61, Y=1320794,99 координаталы 21 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

д) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Нармонка авыл җирлеге чиге Хәерби авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Егорьево, Хәерби һәм Нармонка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пальцовка авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча аска таба 2,0 км уза, алга таба гомуми юнәлештә Мишә елгасы буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба яр буе линиясенә кадәр, аннары 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, шуннан соң күл буйлап 15 м, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, алга таба сазлыкның көньяк кырые буйлап 200 м, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, алга таба сазлыкның көньяк кырые буйлап 100 м канауга кадәр, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм сазлык буйлап 600 м уза. Аннары чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап башта 350 м көньяк-көнбатышка таба, аннары 850 м төньяк-көнбатышка таба Хәерби – Караеш автомобиль юлына кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатыш юнәлештә сазлыкның төньяк кырые буйлап 100 м, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, шуннан соң куаклыкларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, Карадүле – Хәерби – Травкино автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Нармонка авыл җирлеге чиге Егорьево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып 100 м көньяк-көнчыгышка таба Мишә елгасы буйлап, алга таба гомуми юнәлештә 1,3 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап сазлыкка кадәр уза, көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм

сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м бара, аннары сазлык буйлап 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба уза. Алга таба чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км көньяк-көнчыгышка таба, аннары 1,6 км көнбатышка таба, шуннан соң 1,2 км көньяк-көнбатышка таба һәм кабат 700 м көньяк-көнчыгышка таба "Лаеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының аерым торган кишәрлегенә кадәр уза, шуннан соң 85 нче урман кварталының аерым торган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 400 м көнчыгышка таба һәм аннары аның көнчыгыш чиге буйлап 350 м көньякка таба сазлыкка кадәр бара, 100 м көньякка таба сазлык чиге буйлап бара, аннары шул ук юнәлештә 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 85 нче урман кварталына кадәр, алга таба шушы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап гомуми юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

8) 17 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Караеш," сүзен төшереп калдырырга;

б) алтынчы абзацта "Караеш, Хәерби һәм Никольский" сүзләрен "Хәерби, Нармонка һәм Никольский" сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) сигезенче абзацта "48 нче тоташу ноктасына кадәр" сүзләрен "14 нче тоташу ноктасына кадәр Столбище – Атабай автомобиль юлы буйлап 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба, аннары" сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 30 июне
№ 42-ТРЗ